**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Чапшар авылы торак пунктында**
**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**11 ноябрь 2022 ел** **№2**

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына карата, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Чапшар авылы торак пунктында халык җыены **карар бирде**:

1. 100 % күләмендә ташлама каралган I нче төркем инвалидларын, тыл хезмәтчәннәрен, 80 яшьтән узган өлкәннәрне, ялгыз яшәүче, балалары булмаган 70 яшьтән узган өлкәннәрне, Россия Федерациясе кораллы көчләренә мобилизацияләнгән гражданнарны һәм аларның гаилә әгъзаларын исәпкә алмаганда, Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Чапшар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган гражданнарга 2023 нче елда үзарасалымны 1000 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- балалар һәм спорт мәйданчыгы өчен балалар спорт һәм уен җиһазлары сатып алу һәм урнаштыру;

- балалар һәм спорт мәйданчыгын төзекләндерү;

- юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү, авыл клубы һәм мәктәп янында парковка урыннары булдыру;

- урам яктырту өчен электр товарлары сатып алу;

- Чапшар авылында агач кисү, территорияне чистарту һәм җыештыру.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен Норма авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Татарстан Республикасы мунципаль берәмлекләре порталы составындагы Балтач муниципаль районы сайтында бастыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Норма авыл җирлеге башлыгы — Шарипҗанов Р.Н.